| | | |
|---|---|---|
| СОВЕТ<br>САХАРОВСКОГО<br>СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ<br>АЛЕКСЕЕВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН<br>РЕСПУБЛИКАСЫ<br>АЛЕКСЕЕВСК<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫҢ<br>САХАРОВКА АВЫЛ<br>ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**18.12.2024** **№ 36**

**Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Советының 14.08.2023 ел, №10 «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләрен раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен төзекләндерү Кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында» 2024 елның 27 ноябрендәге карар проекты буенча гавами тыңлаулар нәтиҗәләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Сахаровка авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Сахаровка авыл җирлеге Советының 14.08.2023 ел №10 карары белән расланган төзекләндерү Кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- **7 статьяга** түбәндәге эчтәлекле яңа абзац өстәргә:

«**юл сервисы объектлары**-юл хәрәкәтендә катнашучыларга хезмәт күрсәтү өчен билгеләнгән биналар, төзелмәләр, корылмалар, башка объектлар (автозаправка станцияләре, автостанцияләр, автовокзаллар, кунакханәләр, кемпинглар, мотельләр, җәмәгать туклануы пунктлары, техник хезмәт күрсәтү станцияләре, охшаш объектлар, шулай ук аларның эшләве өчен кирәкле ял итү һәм транспорт чараларын куюу урыннары);»;

- **8 статьяга** түбәндәге эчтәлекле 3.1 пунктны өстәргә:

«3.1. Автомобиль юлларының юл буенда яисә алар янында урнашкан сервис объектлары (кибетләр, кафелар, кунакханәләр, АЗСлар, ТХС, ял мәйданчыклары) өчен бүленгән территорияләрне карап тоту һәм җыештыру мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан башкарыла.»;

- түбәндәге эчтәлекле **4.1 бүлекне** өстәргә:

**«4.1 бүлек. «Сервис объектларын карап тоту.**

**15.1 статья**

2. Сервис объектлары территорияләрен карап тоту мондый объектларның хуҗасы (милекчесе) тарафыннан гамәлгә ашырыла.

2. Сервис объектларын һәм аларга якын территорияләрне урнаштыруга һәм карап тотуга таләпләр Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнә.».

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында (https://alekseevskiy.tatarstan.ru/), Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга .

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымда калдырам.

**Сахаровка авыл җирлеге Советы**
**утырышында рәислек итүче,**
**1 нче сайлау округы депутаты** **Н.И. Леденцов**